| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Кадряковского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Кадрәк авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

01.10.2018 Кадрәк авылы № 45-1

Кадрәк авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Кадрәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 10, 11 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 22 ноябрь, 909 нчы карары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадрәк авыл җирлеге Советының «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында»2018 елның 28 августындагы 45-1 номерлы карары, Кадрәк авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 28 августындагы 10 номерлы «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадрәк авыл җирлеге Советы **карар бирде**:

1. 2018 елның 18 ноябренә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадрәк авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

I группа инвалидлар һәм ялгыз яшәүче өлкән кешеләрдән (80 яшькә җиткән), торып укучы студентлардан кала, Кадрәк авыл җирлегендә теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2019 елда үзара салымны 500 сум

күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә юнәлтергә Сез ризамы:

1.Күмү урыннарын оештыру һәм карап тоту.

2.Авыл җирлеге чикләрендә юлларны ремонтлау һәм карап тоту.

3.Авыл җирлеге чикләрендә күперләрне ремонтлау һәм карап тоту.

4.Авыл җирлеге территориясен төзекләндерү.

5.Авыл җирлеге чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү.

ӘЙЕ ЮК».

3. Әлеге карарны Кадрәк авыл җирлеге Советының мәгълүмати стендларында, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

4.Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Совет Рәисе А.А. Михайлов